КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 19 сентябрь г.Казань № 845

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннарны ябып асрауга һәм табигатькә реинтродукцияләүгә рөхсәт бирү тәртибен раслау турында» 2001 ел, 30 гыйнвар, 41 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 ел, 23 апрель, 221 нче; 2005 ел, 23 декабрь, 617 нче; 2012 ел, 17 август, 714 нче; 2014 ел, 19 август, 599 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 949 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннарны ябып асрауга һәм табигатькә реинтродукцияләүгә рөхсәт бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 нче пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1996 ел, 20 август, 714 нче карары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару турында нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2018 ел, 19 апрель, 262 нче карары» сүзләренә алыштырырга;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннарны ябып асрауга һәм табигатькә реинтродукцияләүгә

рөхсәт бирү тәртибенә теркәлгән 2 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәтләр бирү тәртибе турында» 2001 ел, 6 февраль, 57 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 ел, 23 апрель, 221 нче; 2006 ел, 16 ноябрь, 545 нче; 2012 ел, 17 август, 714 нче; 2014 ел, 19 август, 599 нчы; 2016 ел, 26 июль, 510 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 949 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәтләр бирү тәртибенә теркәлгән 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннарны ябып асрауга һәм табигатькә реинтродукцияләүгә рөхсәт бирү тәртибенә
1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 сентябрь, 845 нче карары редакциясендә)

Форма

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән
сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннарны ябып асрауга
һәм табигатькә реинтродукцияләүгә
рөхсәт бирүгә гариза

Татарстан Республикасының
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитеты рәисе
__________________________ ына (енә)

_______________________________________________________________________________
(юридик затның тулы исеме, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
_______________________________________________________________________________
(юридик затның, физик затның тулы адресы, физик затның паспорт мәгълүматлары)
түбәндәге хайваннарны ябып асрауга һәм (яки) табигатькә реинтродукцияләүгә рөхсәт бирүегезне сорыйм _______________________________________________________
(хайваннарның саны һәм нинди төргә каравы, җенесе һәм яше)
_______________________________________________________________________________,
(хайваннарны карап тоту кирәклеген кыскача нигезләү)
_______________________________________________________________________________
(фәнни-тикшеренү темасы кысаларында эшләр башкарган очракта,
_______________________________________________________________________________
әлеге тема расланган гыйльми совет утырышы беркетмәсенең датасы һәм номеры күрсәтелә
________________________________________________________________ бәйле рәвештә,
беркетмәдән тиешле өземтә гаризага теркәлә)
карап тоту _____________________________________________________________________
_______________________________________________________________ территориясендә,
_____________________________________________________ табигатькә реинтродукцияләү
______________________________________________ вакытка кадәр гамәлгә ашырылачак.

Хайваннарны карап тоту һәм (яки) реинтродукцияләү өчен җаваплы ___________
(фамилиясе,

________________________________________________________________________________
исеме, атасының исеме, юридик затлар өчен – вазыйфасы)

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән алынган __________ (датасы) ____________ номерлы мәгълүматлар буенча салымнар, һәм Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар юк.

Гариза бирүченең датасы, имзасы _________________________________

_______________________

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәтләр бирү тәртибенә
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 сентябрь, 845 нче карары редакциясендә)

Форма

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәт бирүгә гариза

Татарстан Республикасының
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитеты рәисе
_________________________ ына (енә)

___________________________________________________________________________
(юридик затның тулы исеме, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

___________________________________________________________________________
(юридик яки физик затның адресы)

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган түбәндәге хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәт бирүегезне сорыйм: ___________________________________________
(үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының сорала торган объектларының

___________________________________________________________________________,
нинди төргә каравы, җенесе һәм яше)

___________________________________________________________________________,

___________________________________________________________________________,
үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектлары әйләнеше кирәклеген һәм максатларын кыскача нигезләү

___________________________________________________________________________.

Хайваннарның һәм үсемлекләрнең нормаль яшәү һәм үсү шартларын тәэмин итү өчен ______________________________________________________
(вольерлар, читлекләр, киртә абзарларның һәм хайваннарны карап тоту һәм ташу өчен

___________________________________________________________________________
җайлаштырылган башка мәйданнарның параметрларын һәм күләмнәрен күрсәтеп,

___________________________________________________________________________.
шартлар тасвирламасы)

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлекләр һәм хайваннар әйләнеше өчен җаваплы: _____________________________________________.

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфаи затлар өчен – вазыйфасы)

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән алынган __________ ____________ номерлы мәгълүматлар буенча салымнар,
(датасы)
җыемнар һәм Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар юк.

Гариза бирүченең датасы, имзасы ____________________________________

________________________________